Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Суркино авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

17 апрель 2023 ел № 2

Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31 августындагы 28 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» 2021 елның 12 маендагы 55нче номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары, 2022 елның 1 мартыннан кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешү нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 10 апрелендәге 02-08-01/178 номерлы протестын карап

Иске Суркино авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31 августындагы 28 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Иске Суркино авылы Үзәк урам, 77 нче йорт; Яңа Суркино авылы, Үзәк урам, 12а нче йорт торак пункт территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Суркино авыл башкарма
комитеты җитәкчесе Н.В. Леонтьев